| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | | **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 233 «31» 03 2021 ел

«Спас муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне чикләү турында» 2017 елның 28 февралендәге 106 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"» 2020 елның 30 декабрендәге 517-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Спас муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турында " 2017 елның 28 февралендәге 106 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.28.1 пунктының егерме дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«федераль дәүләт белем бирү стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, белем бирү стандартлары һәм мөстәкыйль билгеләнә торган таләпләр (алар булганда) турында»

1.2. 3.28.1 пунктының илле бишенче абзацы «әзерлек юнәлеше» сүзләреннән соң «фәнни белгечлек» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин